**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантлары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Социаль әһәмияткә ия проектларны, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә проектларны тормышка ашыра торган граждан җәмгыятен үстерүдә катнашучы коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт ярдәмен камилләштерү максатында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантлары турында» 2021 елның 29 декабрендәге ПУ-1002 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Граждан җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантлары турында»;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымтада китерелгән Граждан җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантлары турында нигезләмәне расларга.»;

в) Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантлары турында нигезләмәдә:

атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Граждан җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантлары турында нигезләмә»;

1 пунктта «грантлары» сүзе алдыннан «Рәисе» сүзен өстәргә;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Грантлар социаль әһәмияткә ия проектларны, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә проектларны тормышка ашыра, түбәндәге юнәлешләрдә эшчәнлек алып бара торган коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә:

а) гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү, аларны социаль яклау;

б) гражданнарның сәламәтлеген саклау, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

в) гаиләгә, ата-аналарга һәм балаларга ярдәм итү;

г) аларны тормышка ашыру «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның

$31^1$ статьясында каралган эшчәнлек төрләрен тәшкил иткән яшьләр проектларына ярдәм итү;

д) яшьләр даирәсендә тискәре социаль күренешләрне кисәтү;

е) балалар һәм яшьләрне ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү;

ж) фән, мәгариф, мәгърифәт өлкәсендә проектларга ярдәм итү;

з) мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә проектларга ярдәм итү;

и) мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә яшь талантларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү;

к) тарихи хәтерне саклау, тарихны бозып күрсәтү омтылышларына каршы көрәшү;

л) кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен, шул исәптән иректән мәхрүм ителгәннәрнең хокукларын яклау;

м) әйләнә-тирә мохитне һәм хайваннар дөньясын саклау;

н) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең су объектларында куркынычсызлыгын тәэмин итү;

о) милләтләр һәм диннәр арасында татулыкны ныгыту, Россиянең традицион рухи-әхлакый хәзинәләрен саклау һәм яклау;

п) татар милли мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү;

р) Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телләрен саклау һәм үстерү өчен шартлар булдыру;

с) чит ил гражданнарының (мигрантларның) җайлашуына ярдәм итү;

т) Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның тарихи-мәдәни мирасын саклау;

у) иҗтимагый дипломатияне үстерү һәм ватандашларга булышлык күрсәтү;

ф) граждан җәмгыяте институтларын үстерү;

х) махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләренә ярдәм күрсәтү.»;

3 пунктта «грантлары» сүзе алдыннан «Рәисе» сүзен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 28 июнь
№ 493